ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

06.03.2019 п.г.т.Алексеевское № 109

**Җирле үзидарә органнарының**
**һәм муниципаль учреждениеләрнең**
**ирекле (волонтерлык) эшчәнлеген**
**оештыручылар, ирекле (волонтерлык)**
**оешмалары белән үзара хезмәттәшлек**
**тәртибен раслау турында**

Россия Федерациясенең «Ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 5 февралендәге 15-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә, «Хәйрия эшчәнлеге һәм иреклелек (волонтерлык) турында» 1995 елның 11 августындагы 135-ФЗ номерлы Федераль законның 17.3 статьясы белән, Алексеевск муниципаль районы Уставының 6 статьясындагы 1 пунктының 30 пунктчасы, 1 пункттагы 5 пунктчасының 12 абзацына нигезләнеп

**карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль учреждениеләренең ирекле (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручылар, ирекле (волонтерлык) оешмалары белән үзара хезмәттәшлек итү тәртибен расларга (Кушымта).
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат Рәсми порталында, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Н. П. Чуринга йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Н.К.Кадыйров**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
__06.03.2019_ № _109_
карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль учреждениеләренең ирекле (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручылар, ирекле (волонтерлык) оешмалары белән үзара хезмәттәшлек итү тәртибе**

1. Ирекле (волонтерлык) эшчәнлеге дигәндә, әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән максатларда эшләрне түләүсез башкару һәм (яки) хезмәт күрсәтү рәвешендәге ирекле эшчәнлек күз алдында тотыла.

2. Җирле үзидарә органнары ирекле теләк белдерүчеләрне (волонтерларны) ирекле (волонтерлык) эшчәнлеген гамәлгә ашыруга җәлеп итәргә хокуклы.

3. Ирекле (волонтерлык) эшчәнлеге түбәндәге максатларда гамәлгә ашырыла:

социаль ярдәм күрсәтү һәм гражданнарны яклау, шул исәптән аз керемле

кешеләрнең матди хәлен яхшырту, эшсезләрнең, инвалидларның һәм үзенең физик яки интеллектуаль үзенчәлекләре аркасында, башка шартлар нигезендә үз хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен мөстәкыйль тормышка ашырырга сәләтле булмаган башка затларның матди хәлен яхшырту максатында;

халыкны табигый бәла-казалар, экологик, сәнәгый һәм башка төрле һәлакәтләр нәтиҗәләрен бетерүгә, бәхетсезлек очракларын булдырмый калуга әзерләү;

табигый бәла-казалардан, экологик, сәнәгый һәм башка катастрофалардан зыян күрүчеләргә, социаль, милли, дини конфликтлар, репрессия корбаннарына, качакларга һәм күченеп килергә мәҗбүр булган кешеләргә ярдәм күрсәтү;

халыклар арасындагы тынычлыкны, дуслыкны һәм татулыкны ныгытуга, социаль, милли, дини конфликтларны кисәтүгә ярдәм итү;

гаиләнең җәмгыятьтәге абруен һәм ролен ныгытуга ярдәм итү;

ана, бала һәм ата булу хокукларын яклауга ярдәм итү;

мәгариф, фән, мәдәният, сәнгать, мәгърифәт, шәхеснең рухи үсешенә ярдәм итү;

гражданнарның сәламәтлеген профилактикалау һәм саклау өлкәсендәге эшчәнлеккә ярдәм итү, шулай ук сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау, гражданнарның әхлакый-психологик хәлен яхшырту;

физик культура һәм спорт өлкәсендә (һөнәри спорттан тыш) эшчәнлекне оештыру һәм (яки) физик затлар тарафыннан түләүсез эшләр башкару һәм (яки) хезмәт күрсәтү рәвешендә физкультура һәм спорт чараларын оештыруда һәм (яки) үткәрүдә катнашу;

әйләнә-тирә мохитне саклау һәм хайваннарны яклау;

тарихи, мәдәни урыннарны, мәдәни яки табигый саклау әһәмияте булган биналарны, объектларны һәм территорияләрне һәм күмү урыннарын саклау һәм тиешле тәртиптә тоту;

халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә белемнәрне пропагандалау;

ятим балаларны, ата - ана каравыннан мәхрүм калган балаларны, караучысыз балаларны, авыр тормыш хәлендә калган балаларны социаль тернәкләндерү,

халыкка түләүсез юридик ярдәм күрсәтү һәм хокукый белем бирү;

ирекле (волонтерлык) эшчәнлегенә ярдәм итү;

балигъ булмаганнарның күзәтүчесез калуын һәм хокук бозуларын профилактикалау эшчәнлегендә катнашу;

балалар һәм яшьләрнең фәнни-техник, сәнгати иҗатын үстерүгә ярдәм итү;

балаларга һәм яшьләргә патриотик, рухи-әхлакый тәрбия бирүгә ярдәм итү;

иҗтимагый әһәмиятле яшьләр инициативасына, проектларга, балалар һәм яшьләр хәрәкәтенә, балалар һәм яшьләр оешмаларына ярдәм күрсәтү;

социаль реклама ясау һәм (яки) тарату эшчәнлегенә ярдәм итү;

гражданнар араында социаль куркынычсызлык тәртипләрен профилактикалауга ярдәм итү.

4. Җирле үзидарә органнары һәм муниципаль учреждениеләр, килешү төзү юлы белән, ирекле (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручы белән үзара хезмәттәшлекне башлап җибәрергә хокуклы.

5. Үзара хезмәттәшлекне тәэмин итү максатларында ирекле (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручылар җирле үзидарә органнарына һәм муниципаль учреждениеләргә ирекле (волонтерлык) эшчәнлеген гамәлгә ашыру буенча язма тәкъдим җибәрергә хокуклы.

Ирекле (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручының тәкъдимендә аның җитәкчесенең һәм вәкилләренең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) һәм элемтәләре;

дәүләт теркәве турында белешмәләр (юридик затлар өчен);

«Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайт адресы;

тәкъдим ителә торган эшчәнлек төрләре исемлеге, аларның тасвирламасы булырга тиеш.

6. Ирекле (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручының күрсәтелгән тәкъдимнәрен карау срогы 20 эш көненнән дә артмаска тиеш.

7. Муниципаль учреждение тарафыннан хуплау турындагы карар чыгару рәвешендә гамәлгә ашырыла торган тәкъдимнәрнең карап тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү турында, аңа уртак эшчәнлек турында Килешү проекты беркетелергә тиеш, яисә муниципаль учреждение хаты белән рәсмиләштерелә торган тәкъдимнән мотивлаштырылган баш тарту беркетелергә һәм бер көн эчендә ирекле (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручы адресына (мөмкинлек булса, электрон почта буенча) җибәрелә тиеш.

8. Ирекле (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручы, муниципаль учреждение тарафыннан ирекле (волонтерлык) эшчәнлеген гамәлгә ашыру турындагы тәкъдимнәре кире кагылган очракта, муниципаль оешманы оештыручы (учредителе) булган җирле үзидарә органына шундый ук тәкъдим белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

9. Ирекле (волонтерлык) оешмалары җирле үзидарә органнары һәм муниципаль учреждениеләр белән уртак эшчәнлек турында килешүләр төзергә

хокуклы.

10. Килешүне карау срогы иректе эшчәнлекне гамәлгә ашыру буенча тәкъдимнәрне хуплаган көннән соң 14 эш көненнән дә артмаска тиеш.

11. Муниципаль учреждение һәм иректе (волонтерлык) оешмасы арасында уртак эшчәнлек турында килешү төзү барышында каршылыклар килеп туган очракта, иректе (волонтерлык) оешмасын оештыручы яисә учреждение җирле үзидарә органнарына мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

12. Каршылыклар ике якның да катнашында һәм, кирәк булган очракта, Алексеевск муниципаль районы Советы каршындагы Иҗтимагый совет һәм муниципаль дәрәҗәдә булдырылган башка киңәшмә органнары вәкилләрен җәлеп итеп карала.

13. Муниципаль учреждение һәм иректе (волонтерлык) оешмасы арасында уртак эшчәнлек турында килешү төзегәндә, учреждение иректе эшчәнлекне оештыручы вәкилләр һәм иректе теләк белдерүчеләр (волонтерлар) белән үзара хезмәттәшлекне оештыру өчен җаваплы хезмәткәр билгеләргә тиеш.

14. Учреждение һәм иректе (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручының уртак эшчәнлеге турында килешүләр иректе эшчәнлек үзенчәлекләрен исәпкә алып, якларның «Хәйрия эшчәнлеге һәм иреклелек (волонтерлык) турында» 1995 елның 11 августындагы 135-ФЗ номерлы Федераль законның 17.1-17.2 статьяларында билгеләнгән уртак эшчәнлек предеты һәм бурычларын, йомгаклау нигезләмәләрен, шул исәптән түбәндәге нигезләмәләрне дә кертеп, билгеләүне күздә тотарга тиеш:

1) Иректе (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручыларның хокуклары:

- учреждение белән килештерелгән эшчәнлек рәвешендә учреждение территориясендә һәм биналарында иректе теләк белдерүчеләр эшчәнлеген гамәлгә ашыру;

- учреждение территориясен төзекләндерү һәм аның торышын яхшырту эшләрен үткәрү, учреждение биналарына ремонт үткәрү.

2) Иректе (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручының вазыйфалары:

- учреждениегә җәлеп ителгән белгечләр, хезмәткәрләр һәм/яки иректе ярдәмчеләр (волонтерлар) исемлеген, аларның фамилиясен, исемен, атасының исемен (булганда) күрсәтеп бирү, кирәк булганда - (яклар килешүе буенча) башка мәгълүматлар тапшыру, шул исәптән:

а) махсус һөнәри күнекмәләр булу турында мәгълүмат;

б) вәкаләтле вәкилне билгеләргә һәм язма мөрәҗәгатьтә бу хакта учреждениегә хәбәр итәргә;

в) Россия Федерациясе законнары нигезендә килешүне үтәү нәтиҗәсендә билгеле булган конфиденциаль һәм шәхси мәгълүматка карата таләпләрне үтәүне тәэмин итәргә;

г) учреждениенең эшен регламентлаучы хокукый нормаларны, шул исәптән учреждениенең эчке тәртип кагыйдәләрен саклауны тәэмин итү;

д) учреждение тарафыннан бирелгән биналарны, саклау урыннарын, техник чараларны, җиһазларны тиешле санитар-гигиена һәм техник хәлдә тотуны тәэмин итү;

е) учреждение белән аның территориясендә гамәлгә ашырыласы һәм клиентлары катнашында үткәреләчәк чаралар планын килештерергә;

ж) учреждениегә башкарылган эшләр һәм чараларның нәтиҗәләре турында хисаплар тапшырырга;

з) психологик ярдәм, психологик реабилитацияләү белән тәэмин итү;

и) ирекле (волонтерлык) эшчәнлеген гамәлгә ашырганда ирекле ярдәмче итеп алган кешенең тормышына һәм сәламәтлегенә зыян китермәүне тәэмин итү.

3) Учреждениенең хокуклары:

- ирекле (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручыны ирекле ярдәмчеләрне (волонтерларны) җәлеп итүгә ихтыяҗ булу турында хәбәр итәргә;

- ирекле (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручыга, ирекле ярдәмчеләргә (волонтерларга) ярдәм итәргә.

4) Учреждениенең бурычлары:

- ирекле ярдәмчеләр (волонтерлар) эшчәнлеген тәэмин итү өчен биналар, шулай ук техник чаралар һәм җиһазлар бирүне тәэмин итәргә;

- ирекле (волонтерлык) эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен тәүлек буе яки билгеләнгән чорда мөмкинлекләр һәм шартлар бирүне тәэмин итәргә;

- ирекле (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручыга ирекле (волонтерлык) эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле чикләүләр һәм хәвеф-хәтәрләр, учреждение эшен регламентлаучы хокукый нормалар, кирәкле режим таләпләре һәм башка кагыйдәләр турында язмача хәбәр итәргә, аларны үтәү таләп ителә торган тиешле башка кагыйдәләр турында ирекле (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручыга хәбәр итәргә, шулай ук аңа үз вакытында әлеге нормаларның һәм кагыйдәләрнең үзгәрүе турында хәбәр итәргә;

- уртак эш барышында барлыкка килгән мәсьәләләрне оператив хәл итү өчен, ирекле (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручының вәкилләре белән эшләү буенча, вәкаләтле хезмәткәрне билгеләргә.

5) Йомгаклау нигезләмәләре:

- ирекле (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручының һәм учреждениенең үзара килешүен үтәгәндә барлыкка килгән проблемалар һәм кыенлыклар турында үз вакытында хәбәр итү, шулай ук ирекле (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручының эшчәнлеге нәтиҗәләре турында бергәләп фикер алышу һәм бәя бирү бурычлары;

- килешүне гамәлгә ашыру, озайту һәм өзү, бәхәсләрне хәл итү, шул исәптән, кирәк булганда, учреждениенең оештыручысы (учредителе) булып торучы җирле үзидарә органын җәлеп итеп үз көченә керү шартлары.

15. Җирле үзидарә органнары 1995 елның 11 августындагы 135-ФЗ номрлы Федераль законда һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында каралган формаларда ирекле (волонтерлык) эшчәнлегенә ярдәм итәләр.

**Эшләр белән идарә итүче** **Г.А. Юсупова**